УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ахтубинская, д. 6, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ
Актүбә ур., 6 нчы йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел.: (8555) 74-30-37, факс: 47-30-25. E-mail: obraz.upr@tatar.ru, сайт: edu.tatar.ru/nkamsk/roo

# ПРИКАЗ

от _____________ 2023 г. № ______

О проведении муниципального конкурса
“Татар малае -2024” ,“Татар кызы – 2024”

В соответствии с планом мероприятий управления образования Исполнительного комитета Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан на 2023-2024 учебный год в целях создания условий для творческой самореализации личности, раскрытия духовного потенциала учащихся, приобщения детей к родному языку, историко-культурному наследию Республики Татарстан

ПРИКАЗЫВАЮ:

1.Провести с 07 декабря 2023 года по 23 января 2024 года муниципальный конкурс “Татар малае - 2024” ,“Татар кызы – 2024” (далее – Конкурс) для обучающихся 1-4 классов общеобразовательных организаций Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан.

2.Утвердить прилагаемое положение о проведении Конкурса.

3.Рекомендовать директорам общеобразовательных организаций НМР РТ обеспечить участие обучающихся в Конкурсе.

4.Директору Базеевой Е.А. (МБОУ «СОШ №7») обеспечить работу организационного комитета и конкурсной комиссии, организовать проведение Конкурса, подведение итогов и награждение победителей, призеров и участников, согласно положению Конкурса.

5.Методисту МБУ «Центр образования» НМР РТ Исмагиловой Р.Р. вести методическое сопровождение и контроль за проведением Конкурса.

6.Методисту МБУ “Центр образования” НМР РТ Яковлевой Л.И.провести торжественную церемонию награждения участников Конкурса с вручением буклетов-фотоальбомов “Национальные сокровища. Милли хәзинәләр” в количестве 30 экземпляров.

7.Контроль за исполнением приказа оставляю за собой.

Исполняющий обязанности
начальника управления образования А.Р.Рамазанова

Исмагилова Р.Р.
8(8555)47-30-38

«РАСЛАНДЫ»
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы

_______ А.Р.Рамазанова
«01» 12 2023г.

«КИЛЕШЕНДЕ»
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы 7 нче гомуми белем бирү мәктәбе директоры

_______ Е.А.Базеева
«___» ________ 2023 г.

Түбән Кама муниципаль районы мәктәпләрендә укучы балалар өчен
“Татар малае-2024” һәм “Татар кызы – 2024” бәйгесенең
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**1.Гомуми нигезләмә**

2023-2024 нче уку елына "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" гы законны тормышка ашыру, балаларны татар (туган) теленә, Татарстан Республикасының тарихи - мәдәни мирасына тарту, эстетик тәрбия бирү, программа - методик һәм дидактик тәэмин итүне камилләштерү максатыннан «Татар малае, татар кызы-2024» бәйгесе (алга таба-конкурс) үткәрелә.

Бәйгедә гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

**2.Бәйгенең максаты һәм бурычы**:

- Түбән Кама районында яшәүче талантлы балаларны ачыклау, аларга ярдәм итү;
- иҗатта үз-үзләрен күрсәтү өчен шартлар тудыру;
- милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне торгызу һәм популярлаштыру;
- яшь талантларның иҗатын пропагандалау;
- телебезгә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру;
- бүгенге буын яшьләренә мәдәни хәзинәләребез нигезендә зәвыклы тәрбия бирү.

**3. Конкурсны оештыручылар**

Конкурсның оештыручысы булып Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе һәм Түбән Кама муниципаль районы 7 нче гомуми белем бирү мәктәбе килә.

## 4. Конкурсның темасы һәм чыгыш ясауга таләпләр :

4.1.Конкурсның темасы: ”Без – татар малайлары һәм кызлары” .

4.2. Конкурста катнашучылар татар телендә биремнәрне үтиләр һәм чыгышларын тәкъдим итәләр.

1 нче бирем: **Визитка “Үзем турында үзем”**

Бәяләүкритерийлары:

- сәхнәгә керү һәм чыгу осталыгы (5 балл);
- тышкы кыяфәте һәм костюмы ( традицион яисә аерым бер стиль белән тегелгән милли киемнән чыгыш ясау) (5 балл);
- музыкаль бизәлеш (5 балл);
- декорация булу (5 балл);
- атрибутика (5 балл) ;
- оригинальлек (5 балл) ,
- артистизм (2-3 минуттан артмаска тиеш) (5 балл).

2 нче бирем: **“Үз телемдә сөйлим”** (Сәнгатьле сөйләү осталыгы. Түбән Кама районы татар шагыйрьләре иҗатыннан бер шигырь) **.**

Бәяләү критерийлары:

- татар телендә дөрес сөйләү (5 балл);
- чыгышның сәнгатьле булуы: дикция, интонация (5 балл);
- сәхнәдә үз-үзеңне иркен тоту (5 балл).

3 нче бирем: **“Татарча җырлыйм әле” яисә** “**Минем биисем килә”бәйгесе.**

**а) “Татарча җырлыйм әле”** бәйгесенә бәяләү критерийлары :

- башкару осталыгы һәм техникасы: диапазон, тавышны кую, ритмны тою, интонацияләрнең чисталыгы һәм яңгырашның сыйфаты, микрофон белән эшләү осталыгы (5 балл).
- актерлык осталыгы: тамашачы белән контакт, башкарылган әсәрне оригиналь рәвештә тәкъдим итү (5 балл).
- башкарылган әсәрнең конкурсантның яшенә туры килүе (5 балл).

б) “**Минем биисем килә” бәйгесенә** бәяләү критерийлары:

- бию осталыгы; костюмы, реквизитлары (5 балл);
- биюнең оригинальлеге ; сәхнә культурасы булу (5 балл).

4 нче бирем: **Конкурс “Оста эшеннән билгеле” (үз кулларың белән ясаган бер әйберне күрсәтү)**

Бәяләү критерийлары:

- технологик яктан оста эшләнгән булуы (10 балл);
- конкурсант үзе әзерләгән булуы шарт (10 балл);
- төгәллек һәм пөхтәлек (10 балл).

**5. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм катнашу шартлары:**

5.1.Конкурста Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем учреждениеләренең 1-4 нче сыйныф укучылары катнаша ала. Конкурс мәктәпләрдә 2023 нче елның 10 нчы декабрьгә кадәр үткәрелә.

5.2. Конкурсны оештыру 3 этаптан тора:

**1 нче этап**: 10 нчы декабрьгә кадәр – мәктәпләрдә сайлап алу турлары ;

**2нче этап:** 12-22 нче декабрь – муниципаль этабы (өстәмә хәбәр ителәчәк);

**3 нче этап:** 23 нче гыйнвар – Гала концерт (бүләкләү тантанасы).

Конкурста чыгыш ясау җирәбә салу тәртибе белән барачак. Конкурста җиңүчеләргә түбәндәге номинацияләрдә дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла:

"Татар малае - 2024" , “Татар кызчыгы-2024”;

"Иң тырыш малай", “ Иң тырыш кызчык”

"Иң сәләтле малай" ;, Иң сәләтле кызчык”

"Иң тапкыр малай”, "Иң тапкыр кызчык”

"Иң шаян малай”, “Иң шаян кызчык”

"Иң оста куллы малай" , “Иң оста куллы кызчык”

"Иң сөйкемле малай" ; "Иң сөйкемле кызчык”

“Моңлы малай”, “Моңлы кызчык”

"Иң уңган малай" ;(конкурс барышында номинацияләр өстәлергә мөмкин)

**6.Жюри:**

**6.1.** Конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм аларның казанышларын бәяләү максатында районы мөгаллимнәр һәм “Ак калфак” иҗтимагый оешмасы вәкилләре катнашында комиссия төзелә.

**7.Гариза бирү тәртибе:**

**7.1.**Гаризаларны 2023 нче елның 11 нче декабрьгә кадәр guzaliya.sh65@mail.ru электрон почтага җибәрергә:

**1.Катнашучының фотографиясе**

**2.Гариза**

**Конкурста катнашу өчен гариза үрнәге**

| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Сыйныфы, туган елы , ае һәм көне | Элемтә өчен телефон номеры, электрон адресы | Мәктәбе | Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Элемтә өчен телефон номеры, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |